2023 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Габдрахман авылы җирлеге Габдрахман авылында гражданнарның үзара салымын кертү турында

ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

28 ноябрь 2022 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Габдрахман авыл җирлегенең Габдрахман авылында гражданнар җыены карар кабул итте:

1. 2023 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Габдрахман авыл җирлегенең Габдрахман авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче һәр балигъ булган кешедән 400 сум күләмендә үзара салым кертергә, Әфганстан Республикасында һәм башка сугыш барган илләрдә интернациональ бурычларын үтәүчеләрдән, шулай ук Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан (ата-аналарыннан, хатыннан, балаларыннан) тыш.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә: су белән тәэмин итү насослары сатып алу, урам яктырткычлары сатып алу, су белән тәэмин итү системасын норматив хәлгә китерү, проект-смета документларын эшләгән өчен түләү, күрсәтелгән эш төрләренә техник күзәтчелек үткәрү һәм җирлек милкенә рәсмиләштерү.

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Габдрахман авылы, Совет урамы, 77 йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Габдрахман авыл җирлеге башлыгы Р.Ш.Мотаһиров

«АБДРАХМАНОВСКИЙ СЕЛЬСКИЙ СОВЕТ»
ИНН 1607002265
КПП 164401001